МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.07.2020 г. Казань № 479 од

Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» Халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

Татар халык җырларын һәм татар композиторлары әсәрләрен пропагандалау, яшьләрне милли мәдәни ядкарьләрне башкаруга җәлеп итү, талантлы яшь башкаручыларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү, аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү максатларында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» Халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында нигезләмәне әлеге боерыкка кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр И.Х.Әюпова

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
2020 елның 24 июлендәге
479 од номерлы
боерыгы белән расланды

Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» Халыкара телевизион
яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» Халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсы (алга таба – Конкурс) турындагы әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы, «Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» Халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын раслау турында» 2020 елның 17 февралендәге 121 номерлы карарларына нигезләнеп эшләнде.

1.2. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасы Мәдәният министр-лыгы (алга таба – Министрлык).

1.3. Конкурсны оештыру эшләрен башкаручы - «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе (алга таба – Филармония).

1.4. Конкурсның мәгълүмати партнерлары – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «ТАТМЕДИА» АҖ) һәм «Яңа Гасыр»телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыяте (алга таба - «Яңа Гасыр» ТРК» АҖ).

1.5. Конкурсны үткәрүне финанслау Министрлыкның җыелма сметасы акчалары хисабына башкарыла.

2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс татар халык җырларын һәм татар композиторларының әсәрләрен пропагандалау, яшьләрне милли мәдәни ядкарьләрне башкаруга җәлеп итү, талант-лы яшь башкаручыларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү, аларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү максатларында үткәрелә.

2.2. Конкурсның Бурычлары:

- татар халык музыкасын һәм музыка сәнгате әсәрләрен тарату һәм популяр-лаштыру;
- татар халык җырларын һәм татар композиторларының әсәрләрен иң яхшы башкаручыларны ачыклау;
- яшьләрнең иҗади сәләтләрен тормышка ашыруда һәм аларны татар музыка мәдәнияте өлкәсендә алга этәрүдә ярдәм итү.

3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста 17 яшьтән алып 35 яшькәчә булган татар музыка әсәрләрен башкаручы солистлар (алга таба – Конкурста катнашучылар) катнаша ала.

3.2. Конкурста профессионал башкаручылар катнаша ала.

3.3. Конкурста катнашучыларның транспортта йөрү, яшәү һәм туклану Конкурска юллаучы як яки Конкурста катнашучы хисабына башкарыла.

4. Бәйгене әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты

Конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Министрлык функцияләре

Министрлык функцияләре:

- Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен чыгымнар сметасын раслау;

- Конкурсны оештыру ягыннан әзерләүне һәм үткәрүне үз компетенциясе чикләрендә тәэмин итү.

6. Филармония функцияләре

Филармония функцияләре:

- Конкурсны үткәрү  барышында оештыру, матди-техник контрольне гамәлгә ашыру;

- сайлап алу турларын үткәрү өчен мәйданчыкларны билгеләү һәм сайлап алу турларын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм Россия Федерациясе субъектлары белән берлектә әзерләү;

- Конкурста катнашу өчен гаризалар җыю;

- Конкурсның һәр турында номинацияләр буенча Конкурста катнашучылар исемлекләрен төзү;

- Конкурс документларын алып бару;

– Конкурсның жюри (алга таба – Жюри) һәм Оештыру комитеты эшен үз компетенциясе чикләрендә тәэмин итү;

- Оештыру комитетына, Министрлыкка Конкурс үткәрүнең барышы турында хәбәр итеп тору;

- массакүләм мәгълүмат чаралары өчен Конкурс турында мәгълүмати материаллар әзерләү.

7. Жюри

7.1. Конкурста җиңүчеләрне сайлап алу өчен мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге белгечләр, җәмәгатьчелек вәкилләре арасыннан рәис, рәис урынбасары,

җаваплы секретарь һәм аның әгъзалары составында 10 (ун) кешедән гыйбарәт Жюри төзелә.

7.2. Жюри әгъзалары составы Министрлык боерыгы белән раслана.

7.3. Жюри эше үз эшчәнлеген утырышлар рәвешендә алып бара. Жюри утырышында аның составының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән ике өлеше булган очракта, ул хокуклы дип санала.

7.4. Жюри рәисе:

- Жюри эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;
- Жюри утырышы датасын, вакытын һәм урынын билгели, утырышларның көн тәртибен раслый;
- Жюри утырышларын алып бара;
- җаваплы секретарьга һәм Жюри әгъзаларына йөкләмәләр бирә;
- Жюри утырышлары тәртибен һәм планын билгели.

Жюри рәисе булмаган очракта, аның вәкаләтләрен Жюри рәисе урынбасары башкара.

7.5. Жюриның җаваплы секретаре:

- Жюри утырышларын әзерләү эшен оештыруны, Жюри утырышының көн тәртибе проектын әзерләүне башкара;
- Жюри утырышында каралырга тиешле мәсьәләләр буенча материаллар җыюны гамәлгә ашыра;
- Жюри утырышлары беркетмәләрен алып бара һәм төзи;
- Жюри документларын теркәү һәм саклауны тәэмин итә.

7.6. Жюри әгъзалары:

- Жюри утырышларында катнашалар;
- Жюри компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга чыгаралар;
- үзләренә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхсән җаваплы булалар.

7.7. Жюри карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Һәр турда җиңүче әлеге Нигезләмәнең 10.2 пунктында билгеләнгән һәр критерий буенча җыелган баллар суммасы буенча билгеләнә.

Баллар исәбе тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

7.8. Конкурс нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләргә рәис кул куя, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм Жюри әгъзалары виза сала. Протоколны рәсмиләштерү срогы Жюри утырышы узган көннән соң 3 эш көнен тәшкил итә.

## 8. Конкурс номинацияләре

8.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

8.1.1. солистлар-вокалчылар арасында (ир-ат һәм хатын-кыз тавышы):

«Академик вокал»: ике беренче премия (ике – беренче урын өчен), ике икенче премия (ике – икенче урын өчен), ике өченче премия (ике – өченче урын өчен);

«Эстрада вокалы»: ике беренче премия (ике – беренче урын өчен), ике икенче премия (ике – икенче урын өчен), ике өченче премия (ике – өченче урын өчен);

«Халык җыры»: ике беренче премия (ике – беренче урын өчен), ике икенче премия (ике – икенче урын өчен), ике өченче премия (ике – өченче урын өчен);

8.1.2. солистлар-уен коралларында уйнаучылар арасында:

«Солист-уен коралында уйнаучы»: өч премия (бер – беренче урын, бер – икенче урын, бер – өченче урын өчен).

## 9. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

9.1. Конкурс 3 елга 1 тапкыр үткәрелә.

9.2. Конкурсны үткәрү сроклары турында мәгълүмат Министрлык Конкурс үткәрү турында карар кабул иткән көннән алып 3 (өч) календарь көн эчендә Министрлыкның рәсми сайтына (http://mincult.tatarstan.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) һәм Филармониянең рәсми сайтына (https://tatfil.ru) (алга таба – Филармониянең рәсми сайты) урнаштырыла.

9.3. Конкурста катнашучылар tm.ilham@mail.ru электрон почтасына яки +7 (919) 690-04-22 WhatsApp, Viber номерына PDF/JPG форматында электрон формада түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча Конкурста катнашуга анкета-гариза (алга таба – анкета-гариза);

паспорт күчермәсе;

диплом күчермәсе (булган очракта);

Конкурсның беренче сайлап алу турында катнашу өчен музыкаль номер языдырылган аудио- һәм/яки видеоматериаллар.

Белешмәләр өчен телефон: (843) 277-19-81 (91).

9.4. Конкурс 3 (өч) турда үткәрелә.

Конкурсның беренче (сайлап алу) туры турыдан-туры яки читтән торып катнашып үткәрелә.

Турыдан-туры катнашу Конкурста катнашучыларны, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә һәм Россия Федерациясе субъектларында күчмә караулар барышында әлеге Нигезләмәнең 9.3 пунктында каралган тапшырылган анкета-гаризага һәм аңа теркәлгән документларга нигезләнеп, Жюри тарафыннан сайлап алуны күздә тота.

Читтән торып катнашу турыдан-туры катнашуны үткәрү мөмкин булмаганда уздырыла һәм әлеге Нигезләмәнең 9.3 пунктында каралган анкета-гаризага һәм аңа теркәлгән документларга нигезләнеп, аудио- һәм (яки) видеоматериалларны тыңлауны һәм (яки) карауны күздә тота.

Һәр номинация буенча рейтингта беренче 30 урынны алган Конкурста катнашучылар Конкурсның беренче туры җиңүчеләре була.

Конкурсның беренче туры җиңүчеләре исемлеге Министрлыкның һәм Филармониянең рәсми сайтларына урнаштырыла.

Конкурсның беренче туры җиңүчеләре Конкурсның икенче турына үтә.

9.5. Конкурсның икенче туры Конкурсның беренче туры тәмамланганнан соң 10 календарь көннән соң үткәрелә.

Һәр номинация буенча рейтингта беренче биш урынны алган Конкурста катнашучылар Конкурсның икенче туры җиңүчеләре була.

Конкурсның икенче туры җиңүчеләре Конкурсның өченче турына үтә.

Конкурсның өченче турына узмаган катнашучылар Конкурста катнашучы дипломы белән бүләкләнә.

9.6. Конкурсның икенче һәм өченче турларын үткәрү даталары турында мәгълүмат Министрлыкның һәм Филармониянең рәсми сайтларына Конкурсның икенче һәм өченче турлары башланганчы 14 календарь көн кала урнаштырыла.

9.7. Жюри баллар суммасы буенча әлеге Нигезләмәнең 10.2 пунктында расланган критерийлар нигезендә һәр номинациядә катнашучылар рейтингын төзи.

Һәр номинация буенча рейтингта беренче 3 урынны алган Конкурста катнашучылар Конкурсның өченче туры җиңүчеләре була.

9.8. Конкурсның өченче турында тамашачыларны интерактив тавыш бирдерү юлы белән телевизион эфирда чыгыш ясау нәтиҗәләре буенча иң күп тавыш җыюга нигезләнеп, тамашачылар мәхәббәте призы иясе билгеләнә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүче тавышы хәлиткеч була.

9.9. Конкурста җиңүчеләр исемлеге Жюри беркетмәсе белән рәсмиләштерелә һәм 2 (ике) эш көне эчендә Жюри җаваплы секретаре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла. Беркетмәне рәсмиләштерү срогы Жюри утырышы уздырылган көннән соң 3 (өч) эш көне тәшкил итә.

## 10. Конкурста катнашучыларга таләпләр һәм конкурс критерийлары

10.1. Конкурста катнашучыларга башкарыла торган программа буенча таләпләр:

«Академик вокал» номинациясендә – Конкурсның һәр турында, өченче турдан тыш, әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган тәкъдим ителә торган исемлек нигезендә татар композиторлары музыкасына икешәр классик әсәр (романслар, арияләр, ариозо) башкарыла;

Конкурсның өченче турында «Академик вокал» номинациясендә әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган тәкъдим ителә торган исемлек нигезендә татар композиторлары музыкасына бер классик әсәр (романслар, арияләр, ариозо) башкарыла;

«Эстрада вокалы» номинациясендә – Конкурсның һәр турында, өченче турдан тыш, әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган тәкъдим ителә торган исемлек нигезендә татар композиторлары музыкасына бер әсәр һәм хәзерге заман татар композиторларының бер әсәре башкарыла;

Конкурсның өченче турында «Эстрада вокалы» номинациясендә әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада каралган тәкъдим ителә торган исемлек нигезендә татар композиторлары музыкасына бер әсәр яки хәзерге заман татар композиторларының бер әсәре башкарыла;

«Халык җыры» номинациясендә – Конкурсның һәр турында, өченче турдан тыш, икешәр татар халык җыры башкарыла;

Конкурсның өченче турында «Халык җыры» номинациясендә бер татар халык җыры башкарыла.

«Академик вокал», «Эстрада вокалы», «Халык җыры» номинацияләрендә барлык әсәрләр дә татар телендә башкарыла.

«Солист-уен коралында уйнаучы» номинациясендә – Конкурсның һәр турында Конкурста катнашучы татар композиторы музыкасына берәр әсәр яки эшкәртелгән берәр татар халык көен уйный.

10.2. Конкурсның һәр турында Жюри өчен Конкурс критерийлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Конкурста катнашучыларның башкару осталыгы (техника, эмоциональлек) (0-10 балл);

чыгышның үзенчәлекле булуы (костюм, реквизит, яктылык җиһазларын куллану, музыкаль ярдәм) (0-10 балл);

сәхнә культурасы (актерлык осталыгы, сәнгати образ тудыра торган сәнгать чараларын куллану) (0-10 балл).

## 11. Конкурска йомгак ясау һәм бүләкләү

11.1. Жюри, Конкурста катнашучыларның чыгышлары Конкурс таләпләренә һәм аның критерийларына туры килмәгән очракта, теге яки бу номинациядә урыннар бирмәү хокукына ия.

11.2. Жюри беркетмәсенә нигезләнеп, Министрлыкка беркетмә кергән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә Конкурста җиңүчеләр турында Министрлык боерыгы чыгарыла.

11.3. Конкурста җиңүчеләр исемлеге боерыкка кул куелганнан соң 3 (өч) эш көне эчендә Филармониянең һәм Министрлыкның рәсми сайтларына урнаштырыла.

11.4. Оештыру комитеты Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү өчен Конкурсның гала-концертын оештыра.

11.5. Конкурсның гала-концерты датасына кадәр 10 (ун) календарь көннән соңга калмыйча, Филармониянең һәм Министрлыкның рәсми сайтларына Конкурсның гала-концертын үткәрү урыны һәм вакыты турында мәгълүмат урнаштырыла.

11.6. Конкурста җиңүчеләр дипломнар, акчалата бүләкләр һәм истәлекле билгеләр белән бүләкләнә.

11.7. Һәр номинация буенча акчалата премияләр күләме: 1 урын өчен – 50,0 мең сум, 2 урын өчен – 30,0 мең сум, 3 урын өчен – 20,0 мең сум.

11.8. Тамашачылар мәхәббәте бүләге иясенә истәлекле бүләк тапшырыла.

11.9. Министрлык оешмалар һәм предприятиеләрнең Конкурста катнашучылар өчен махсус бүләкләр булдыру турындагы тәкъдимнәрен килештерә.

Илһам Шакиров исемендәге
«Татар моңы» Халыкара телевизион
яшь башкаручылар конкурсын
әзерләү һәм үткәрү турында ни-
гезләмәгә
1 нче кушымта

(Форма)

Илһам Шакиров исемендәге «Татар моңы» Халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсында катнашуга
АНКЕТА-ГАРИЗА

Башкаручы:
Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
_______________________________________________________________

Туган көне һәм урыны:
_______________________________________________________________

Яшәү урыны адресы:
_______________________________________________________________

Телефон: e-mail:_________________________________________________

Паспорт мәгълүматлары:
_______________________________________________________________

Салым түләүченең идентификация номеры (ИНН) (булган очракта):
_______________________________________________________________

Дәүләт пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (СНИЛС):
_______________________________________________________________

Белем (белем бирү оешмасының исеме, тәмамлау елы):___
_______________________________________________________________

Эш/уку урыны:
_______________________________________________________________

Башка фестивальләрдә, конкурсларда катнашу турында белешмәләр:
_______________________________________________________________

Конкурска юллаучы оешма җитәкчесе турында белешмәләр (булган очракта ):
Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта ) һәм вазыйфасы:___________________________________________________________

Телефон: e-mail: _______________________________________________

Конкурста катнашуга чакыруны кем исеменә җибәрергә (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), вазыйфасы, почта адресы, электрон почта адресы, телефон, факс):
_______________________________________________________________

Аккомпаниаторга ихтыяҗ: баян, фортепиано *(ассызыкларга кирәк)*.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә каршы килмим.

Тутыру датасы ___________________________
Шәхси имза ______________ / ________________________/

Конкурска юллаучы
оешма җитәкченең имзасы (булган очракта) _______________ / __________________

М. У. (булган очракта)

Илһам Шакиров исемендәге
«Татар моңы» Халыкара телевизион
яшь башкаручылар конкурсын
әзерләү һәм үткәрү турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

БАШКАРУ ӨЧЕН ӘСӘРЛӘРЕ ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ТАТАР КОМПОЗИТОРЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

Абдуллин Рәшит Фарук улы,
Әхиярова Резедә Зәки кызы,
Әхмәдиев Фәтхерахман,
Әхмәтов Фасил Әхмәт улы,
Байтиряков Илһам Илгиз улы,
Бакиров Әнвәр Закир улы,
Вәлиуллин Аллаһиар Гарифулла улы,
Вәлиуллин Хөснулла Вәлиулла улы,
Габәши Солтан Хәсән улы,
Галимова Эльмира Мөнир кызы,
Гатауллин Риф Хаббул улы,
Гыйбадуллин Зиннур Хисмәт улы,
Дәүләтшин Илфат Мәҗит улы,
Еникеев Ренат Әхмәт улы,
Җиһанов Нәҗип Гаяз улы,
Закиров Илгиз Тимершәех улы,
Имашев Мәсхүт Габдрахман улы,
Кәлимуллин Рәшит Фәһим улы,
Камалов Ильяс Фәйзерахман улы,
Ключарев Александр Сергеевич,
Мәҗитов Илгиз Габидулла улы,
Мәҗитов Шакир Хафиз улы,
Макаров Марс Андреевич,
Монасыйпов Алмаз Закир улы,
Мортазин Фирзәр Солтан улы,
Мозаффаров Мансур Әхмәт улы,
Мөлеков Бату Гатаулла улы,
Низамов Эльмир Җәүдәт улы,
Садыйкова Сара Гариф кызы,
Сәйдәшев Салих Җамалетдин улы,
Таһирова Лилия Ромел кызы,
Тимербулатов Шамил Харис улы,
Усманов Оскар Вадимович,
Фәйзи Җәүдәт Харис улы,

Хатыйпов Фәрит Хәнәфи улы,
Хәбибуллин Заһит Вәли улы,
Хәйретдинов Зөфәр Гыйльметдин улы,
Хисамов Илфат Нигъмәт улы,
Шакиров Илһам Гыйльметдин улы,
Шәрифуллин Шамил Камил улы,
Яруллин Мирсәид Заһидулла улы,
Яруллин Фәрит Заһидулла улы,
Яхин Рөстәм Мөхәммәтхаҗи улы.